# *РЕНАТ ХАРИСНЫҢ «ТУКАЙНЫҢ МӘХӘББӘТ ТӨШЛӘРЕ» ДРАМАТИК ПОЭМАСЫ*



Эшне башкарды: Урманчеева Розалина Эльбрус кызы
Кәримова Рәзинә Илгиз кызы.



- Шагыйрь, РФнең Дәүләт премиясе иясе, Г.Тукай премиясе лауреаты Ренат Мәгъсүм улы Харисов 1941 елның 6 нчы маенда Ульян өлкәсендә туа. КДПУ тәмамлый.
- 1963-1964 нче елларда Арча педагогика көллиятендә укыта. “Казан утлары” журналы, “Татарстан хәбәрләре” газеталары баш мөхәррире, Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе, ТАССРның мәдәният министры урынбасары, Дәүләт Советы председателе урынбасары булып эшли.
- 40 шигырь һәм поэмалар, музыкаль сәхнә әсәрләре җыентыклары һәм либреттолар авторы.



Шагыйрь үзенең шигырь, поэмаларында һәм күпсанлы әдәби тәнкыйть әсәрләрендә татар халкының тарихи яшәеше, кеше шәхесенең тормыштагы урыны, аның табигать, җәмгыять, хакимият белән мөнәсәбәте, буыннар дәвамлылыгы турында уйлана, заманның әхлакый, рухи, иҗтимагый күренешләренә үзенең фәлсәфи һәм гражданлык карашын белдерә.

***Программада темага бирелгән сәгатьләр саны***

- Ренат Харис “Тукайның мәхәббәт төшләре”.
- 11 нче сыйныф, 2 дәрес.
- Дәреслек: А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н. Галиуллин, Ф.Ә.Ганиева, Н.Г.Юзиев. Әдәбият. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек. –Казан: “Татарстан китап нәшрияты”, 2011.
- Хрестоматия: А.Г.Әхмәдуллин, Т.Н.Галиуллин, Н.Г. Юзиев. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен әдәбияттан хрестоматия. - Казан: “Татарстан китап нәшрияты”, 2005.

# ***Максатлар:***

1) дидактик: Сюжет сызыгын үзләштерү (Вакыйгаларны аерып алу. Уку мәсьәләсен куеп, поэмага анализ ясарга өйрәнү. Күтәрелгән теманы, проблеманы, идеяне укучылардан таптыру.) Р.Харисның биграфиясе белән танышу.

2) үстерешле: Фикер эшчәнлеге өчен җирлек тудыру. Фикреләрне гомумиләштереп оештыру. Анализ вакытында туган фикерләрне таркатырга, чагыштырыга өйрәнү. Иҗади фикерләүне үстерү.

3) тәрбияви: Тормыш тәҗрибәсе туплау, геройларның гамәлләренә бәя биреп, яшәү фәлсәфәсе турында уйлануны булдыру. Тугрылык, хөрмәт хисләрен үстерү, бер-береңнең кадерен белергә өйрәнү. Сәнгать әсәре тудырган Р.Хариска ихтирам хисләре тудыру.

**1 нче дәрес:**



## Р.Харисның “Тукайның мәхәббәт төшләре” поэмасының сюжеты

- Поэма
  - Лирик поэма
    - Хис-кичерешләр образлар сурәтләнә

  - Лиро-эпик поэма
    - Вакыйгалар, геройлар

  - Драматик поэма
    - Вакыйгалар, геройлар, конфликт



***Ренат Харисның “Тукайның мәхәббәт төшләре” драматик поэма, чөнки:***

- ***Күләмле тезмә әсәр;***
- ***Катнашучы персонажлар бар;***
- ***Ремаркалар***

***( “Ишегалдына Зәйтүнә чыга. Аны күрү белән Тукай китеп бара”)***

# Сюжет сызыгы

- Һәркемнең бар үз Тукае;
- Тукайның беренче төше;
- Тукайның Фатих белән “Әльихлас” та эшләве;
- Кызларның Тукайны күрергә килүе;
- Тукайның икенче төше;
- “Шәрыкъ клуб”ындагы чыгыш;
- Тукайның өченче төше;
- Зәйтүнәнең Чистайга китүе.

# Модельләштерү:

1.Тукайның өч өне
2.Тукайның өч төше



# Тукайның өч өне

•“Шәрыкъ клубы”нда. Әмирхан, Зәйтүнә, скрипкачы
•Пристаньда. Зәйтүнә, ир кеше
•“Әльихлас” редакциясендә. Әмирхан, Зәйтүнә, Бибиҗамал

- Тукайның 3 төше
  - 1.Курай
  - Фәрештә (Газраил)
  - Тукайның сагышы ( тормыштан кәнәгать булмавы, мәхәббәт турында уйлануы)
  - Курай, Зәйтүнә, Газраил (мәхәббәт аңлату, мәхәббәт ялкыны-гүр салкыны, мәхәббәт-илһамчы, үлем-яшәтү камчысы)
  - Курай, Шүрәле, Газраил, Апуш, Карт (бала-чагын искә төшерү, җәмгыятьтә барган “уеннар”, ләззәт тату, Тукайның Апушны күзәтүе

# Өй эше

- Репродуктив:
- Поэманың сюжетын сөйләргә өйрәнергә
- Конструктив:
- Г.Тукай образына характеристика бирергә
- Иҗади эшчәнлек:
- Поэманың сюжеты буенча рәсем ясарга, шигырь язарга



## 2 нче дәрес:

Ренат Харисның “Тукайның мәхәббәт төшләре” поэмасына анализ

# Образлар һәм алар арасындагы бәйләнеш

- Тукай
  - Зәйтүнә
  - Әмирхан
  - Ир кеше
  - Апуш
  - Шүрәле
  - Газраил

# Хисне ачыклау

- Хис: мәхәббәт хисе.
- Хиснең дәрәҗәсе: мәхәббәт хисе шул хәтле югары ки, хәтта Тукай Зәйтүнәне бәхетсез итмәү өчен, мәхәббәтеннән баш тарта



Конфликт

- Тукайның үзендә (эчке конфликт)

Чишелеш

- Зәйтүнәнең Чистайга китүе

# Символлар, тел-сурәтләү чаралары

- Төш ишегеп ачу – әкияти алым
- Иң якты нурлы шәм – Зәйтүнә
- Курай уйнау, Газраилне күрү – үлем-җитемгә
- Такмаклар әйтешү – матур гореф-гадәт, җор телле булу
- Янып торучы шәм образы – шагыйрь гомеренең кыскалыгы
- “Үсмер аксакалыбыз” – башың яшь булса да, гомер йөгең йөз яшәгән картларныкы

# Модельләштерү

- Темасы:
- Тукайның ачы язмышы турында

- Идеясе:
- Һәркемнең бар үз Тукае

- Проблемасы: Тукайның фаҗигале мәхәббәте

- Автор проблемасы
  - Мәхәббәтнең төрле булуы
  - Татар язмышы
  - Әдәбият язмышы
  - Иҗат итеп тамак туйдырып булмый
  - сәяси
  - Сүз ирег е проблемасы
  - Чын мәхәббәтнең ләззәткә әверелүе
  - әхлак

- Өй эше
  - Репродуктив: Ренат Харисның биографиясен сөйләргә өйрәнергә
  - Конструктив: Г.Тукайның әдәби әсәрләрдә бирелеше. Кимендә 4 әсәр.
  - Иҗади эшчәнлек:
  - “Һәркемнең бар үз Тукае” дигән темага сочинение язарга

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

